КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 2 ноябрь г.Казань № 1039

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 февраль, 38 нче; 2007 ел, 13 июль, 297 нче; 2009 ел, 23 март, 161 нче; 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 22 февраль, 92 нче; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2011 ел, 6 июнь, 452 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 750 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 29 март, 250 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2014 ел, 12 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 3 декабрь, 940 нчы; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче, 2016 ел, 20 август, 578 нче; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 19 июль, 508 нче; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2017 ел, 15 декабрь, 999 нчы; 2017 ел, 29 декабрь, 1118 нче; 2018 ел, 12 июль, 565 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 8 август, 643 нче; 2019 ел, 16 март, 185 нче; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 24 июнь, 509 нчы; 2019 ел, 19 июль, 605 нче; 2019 ел, 11 сентябрь, 814 нче; 2020 ел, 28 апрель, 344 нче; 2020 ел, 26 июнь, 531 нче; 2020 ел, 22 декабрь, 1177 нче карарлары белән кертелгән

үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«01.05.05» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының гамәлдә булуы туктатылган Татарстан Республикасының кайбер муниципаль берәмлекләрендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

«01.05.05» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | «01.05.06 | «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының гамәлдә булуы туктатылган Татарстан Республикасының кайбер муниципаль берәмлекләрендә күпфатирлы йортлар төзү өчен кооператив әгъзалары акчаларын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | ТР Дәүләт төзелеш күзәт-челеге»; | | | | |

«01.06.11» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге)»;

«01.06.11.01» «Су объектларыннан (федераль дәүләт күзәтчелегендә булырга тиешле су объектларыннан тыш) файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә, шулай ук файдалануы һәм саклануы төбәк дәүләт күзәтчелегендә булырга тиешле су объектларында урнашкан гидроэнергетика объектларының саклау зоналары чикләрендә

судан файдаланунын һәм яр буе полосасы участокларыннан (шул исәптән гидроэнергетика объектлары янында булган участоклардан) файдаланунын махсус шартларын үтәүгә төбәк дәүләт күзәтчелеге», «01.06.11.02» «Төбәк дәүләт экология күзәтчелегендә булырга тиешле хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек объектларында атмосфера һавасын саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге», «01.06.11.03» «Төбәк дәүләт экология күзәтчелегендә булырга тиешле хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге», «01.06.11.04» «Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә, аларны нәтиҗәле файдалануга һәм саклауга төбәк дәүләт күзәтчелеге», «01.06.11.05» «Үзәкләштерелгән су чыгару системасы аша агызып төшерелә торган суларны чыгаруга төбәк дәүләт экология күзәтчелеге» дигән юллар үз көчен югалткан дип танырга;

«01.06.12» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау, торгызу һәм алардан файдалану өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

«01.06.13» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле күзәтчелеге (табигать дәвалау ресурсларын, дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны санитария (тау санитариясе) саклавын тәэмин итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген кертеп)»;

«01.06.14» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Урман фонды җирләрендә федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге)»;

«01.06.17» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | «01.06.18 | Татарстан Республикасы территориясендә федераль дәүләт аучылык контроле (күзәтчелеге) (федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш) | ТР Биоресурслар буенча ДК | | | |
| | | | | | | 01.06.19 | Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) | ТР ЭТБМ»; | | | |

«01.08.01» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

«01.13» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | «01.13 | Хезмәт белән идарә итү | ТР ХХЭб ТИСЯ | 01.13.01 | Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | ТР ХХЭб ТИСЯ»; | | | |

«01.17» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | «01.17 | Архив эше белән идарә итү | ТР Архив эше буенча ДК | 01.17.01 | Архив эше турындагы законнарның үтәлешенә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | ТР Архив эше буенча ДК»; | | | |

«02.01.04» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә вәкаләтләрне тормышка ашыруга дәүләт күзәтчелеге»;

«03.03.03» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

«03.03.05» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

«03.03.06» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә вәкаләтләрне тормышка ашыруга дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

«03.03.07» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус юл транспортын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм махсус юл транспортыннан файдалану кагыйдәләре үтәлешенә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

«04.01.02» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге)»;

«04.03.06» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәдәни мирас объектларын (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектларыннан тыш) саклау өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

«04.03.07» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларының, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, ачыкланган мәдәни мирас объектларының торышы, аларны карап тоту, саклау, куллану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклауга төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

«04.03.07» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | «04.03.08 | Россия Федерациясе Музей фондының торышына төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | ТР ММ»; | | |

«04.05.02» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашу урыны буенча теркәлгән, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларга (яшәү урыны буенча теркәлгән индивидуаль эшмәкәрләргә) («Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 7 пунктында күрсәтелгән оешмалардан тыш) карата мәгариф өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм мәгариф өлкәсендә җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләрне тормышка ашыруга дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

«04.06» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | «04.06 | Социаль яклау идарәсе | ТР ХХЭб ТИСЯ | 04.06.01 | Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | ТР ХХЭбТИСЯ »; | | | |

«04.07.01» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үз вәкаләтләре чикләрендә балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмалары реестрында булган балалар ялын һәм аларны сәламәтләндерү оешмалары турындагы мәгълүматларның дөреслегенә, актуальлегенә һәм тулылыгына төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

«03.02.04.1» юлының 11 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хайваннар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

«03.02.06» «Нәселле терлекчелек өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге» юлы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына норматив хокукый актларны әлеге карарга туры китерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин